ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.10.2020 ел Баулы шәһәре №207

2021 елга Баулы муниципаль районының
балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә
өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында
өстәмә белем бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны
раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы (2012 елның 13 февралендәге ред.) “Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында”гы карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021 елга расларга:

кушымтадагы Баулы муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1нче пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 30 октябрендәге
207 номерлы карарына
кушымта

Баулы муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Өч еллык укыту | Дүрт еллык укыту | Биш еллык укыту | Җиде еллык укыту | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җире | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җире | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җире | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җире | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Бию сәнгате | шәһәр җире | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Бию сәнгате | авыл җире | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җире | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җире | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җире | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җире | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җире | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җире | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җире | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җире | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |

________________